| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ФЕДОТОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ФЕДОТОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 2 октябре № 26

Федотовка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, Тимәшавыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар КАРАР БИРДЕ:

1. 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. «2019 елда Федотовка авылында 18 яшькә җиткән һәр гражданнан 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

- торак пунктындагы юлларны карап тоту
-авыл җирлеге чикләрендә күперләрне ремонтлау
- авыл җирлеге чикләрендә суүткәргеч линияне карап тоту.

« Әйе Юк».

3. Әлеге карарны Федотовка авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Федотовка авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы В.И.Павлова